**СОВЕТ НОВОМЕЛЬКЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА МƏЛКƏН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**423725, Республика Татарстан Мензелинский район, с.Новый Мелькен, ул.Школьная, д.17а**

**423725, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы Яңа Мәлкән авылы, Школьная урамы, 17а**

телефон: (85555) 2-37-25. E-mail Nmel.Mnz@tatar.ru

КАРАР

№ 1 25.09.2018ел

**Яңа Мәлкән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, “Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында” Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 18 сентябрендәге 38 номерлы карары һәм “Референдум үткәрү турында” Татарстан Республикасы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советы карары нигезендә

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мәлкән авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:«Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге торак пунктларында 2019 елда 1 һәм 2 төркем инвалидлардан тыш, Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге ("Яңа Мәлкән авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге) составына керүче торак пунктларда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, Бөек Ватан сугышы ветераннары ,

сугыш хәрәкәтләре, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнар, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

2.1 Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
-Яңа Мәлкән торак пунктында чишмәләрне төзекләндерү,
Яңа Мәлкән һәм Дусай-Кичү торак пунктларында мәгълүмати стендлар ясау һәм урнаштыру.
2.2. Җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә:
-Дусай- Кичү торак пунктларында яшәүчеләр күпләп ял итә торган урыннарны тәртипкә китерү.
2.3. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә:
-скважиналар өчен тирән насослар сатып алу һәм урнаштыру.

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Минзәлә муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.
5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

ТР Минзәлә муниципаль районыны
Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы Нәҗметдинов З.И.